ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**АКБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
БАШЛЫГЫ
423958 Ютазы районы,
Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 1
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
**АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423958 Ютазинский район
село Акбаш ул.Школьная, д.1
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 1 03.11. 2021 года.

2022 елда Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендәге
Акбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елның “19”ноябрендә 18:00 сәгатьтә Акбаш авыл мәдәният йорты

бинасы янында, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Акбаш торак пункты, Мәктәп урамы, 17 йорт адресы буенча 2022 елда Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Акбаш торак пунктында зыярат коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

- Акбаш торак пунктында аыыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү нигезендә түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Акбаш авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Акбаш авыл җирлегендәге мәгълумат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы Акбаш
Авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Синәгатуллина